**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

28 август 2023 ел **Чирмешән авылы** №261

«Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милкендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү рекреацион зоналарын булдыру һәм куллану кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 03 августындагы №562 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 98 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы №486-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 03 августындагы №562 карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милкендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү өчен рекреацион зоналар булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 9-11 абзацларын яңа редакциядә бәян итәргә: «Рекреацион билгеләнештәге җирләргә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган җирләр керә (туризм, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту). Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар булдыру рөхсәт ителә. Мондый объектлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Җир кишәрлекләре хуҗалары, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләре арендаторлары белән килешү буенча урнаштырылган юллардан, сукмаклардан һәм трассалардан файдалану сервитутлар нигезендә башкарылырга мөмкин, шул ук вакытта күрсәтелгән җир кишәрлекләре кулланыштан алынмый.

Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә мондый җирләрне һәм аларда урнашкан объектларны, шул исәптән рөхсәт ителгән җир участокларын, рөхсәт ителгән төзелешне саклау һәм кулллануның билгеләнгән режимын үтәгәндә хуҗалык эшчәнлеге рөхсәт ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов